**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен гамәлгә кую турында» 1993 елның 16 апрелендәге ПУ-206 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 1999 елның 9 мартындагы ПУ-147 номерлы, 2000 елның 13 декабрендәге ПУ-979 номерлы, 2001 елның 6 апрелендәге ПУ-265 номерлы, 2005 елның 24 декабрендәге ПУ-514 номерлы, 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-129 номерлы, 2007 елның 12 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы, 2008 елның 20 мартындагы ПУ-120 номерлы, 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1232 номерлы, 2014 елның 9 декабрендәге ПУ-1120 номерлы һәм 2017 елның 1 февралендәге ПУ-88 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре турында нигезләмәгә, 9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«9. Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен гамәлгә кую турында Татарстан Республикасы Президенты Указы Татарстан Республикасы Президентының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 27 ноябрь
№ ПУ-806